РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
АЛЬМЕТЬЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ӘЛМӘТ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«19» декабрь 2025 ел г. Альметьевск № 2949

Әлмәт муниципаль районы Башкарма
комитетының «Әлмәт муниципаль районы
(Әлмәт шәһәре) үзәгеннән
11 километр ераклыкта урнашкан
Әлмәт муниципаль районының
авыл торак пунктларына беренче
кирәк-ярак товарларын китерү
белән бәйле кулланучылар кооперациясе
оешмаларының чыгымнары өлешен
каплауга Әлмәт муниципаль районы
бюджетыннан субсидия бирү
тәртибе турында» 2024 елның
14 августындагы 2664 номерлы
карарына үзгәрешләр кертү турында

Субсидияләр, шул исәптән юридик затларга, шәхси эшмәкәрләргә, товарлар, эшләр, хезмәтләр җитештерүче физик затларга субсидияләр рәвешендә грантлар бирүне, күрсәтелгән субсидияләрне алучыларны, шул исәптән субсидияләр рәвешендә грантларны сайлап алуны үткәрүне җайга сала торган норматив хокукый актларга, муниципаль хокукый актларга гомуми таләпләрне раслау турында» Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2023 елның 25 октябрендәге 1782 номерлы карары нигезендә, «Татарстан Республикасы район үзәкләреннән 11 километр ераклыкта урнашкан Татарстан Республикасы авыл торак пунктларына беренче кирәк-ярак товарларын китерүгә бәйле кулланучылар кооперациясе оешмаларының чыгымнары өлешен каплауга Татарстан Республикасы бюджетыннан башка бюджетара трансфертлар бирү тәртибен раслау турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2017 елның 20 ноябрендәге 887 номерлы карарын үтәү йөзеннән

БАШКАРМА КОМИТЕТ КАРАР БИРӘ:

1. Әлмәт муниципаль районы Башкарма комитетының «Әлмәт муниципаль районы (Әлмәт шәһәре) үзәгеннән 11 километр ераклыкта урнашкан Әлмәт муниципаль районының авыл торак пунктларына беренче кирәк-ярак товарларын китерү белән бәйле кулланучылар кооперациясе оешмаларының чыгымнары өлешен каплауга Әлмәт муниципаль районы бюджетыннан субсидия бирү тәртибе турында» 2024 елның 14 августындагы

заказ № 4553-940

2664 номерлы карарына (Әлмәт муниципаль районы Башкарма комитетының 2025 елның 22 июлендәге 1772 номерлы карары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

тәртипкә 3 нче кушымтаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

««Әлмәт муниципаль районы
(Әлмәт шәһәре) үзәгеннән
11 километр ераклыкта урнашкан
Әлмәт муниципаль районының
авыл торак пунктларына беренче
кирәк-ярак товарларын китерү
белән бәйле кулланучылар кооперациясе
оешмаларының чыгымнары өлешен
каплауга Әлмәт муниципаль районы
бюджетыннан субсидия бирү
тәртибенә 3 нче кушымта

Әлмәт муниципаль районы (Әлмәт шәһәре) үзәгеннән 11 километр ераклыкта урнашкан Әлмәт муниципаль районының авыл торак пунктларына беренче кирәк-ярак товарларын китерүгә бәйле рәвештә кулланучылар кооперациясе оешмаларының чыгымнары өлешен каплауга Әлмәт муниципаль районы бюджетыннан субсидия алу хокукын дәгъвалаучы юридик затларны, индивидуаль эшкуарларны, физик затларны сайлап алуны гамәлгә ашыручы
КОМИССИИ СОСТАВЫ

Каюмов А.М. – комиссия рәисе, Әлмәт муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесе;

Ямалетдинов А.Ә. - рәис урынбасары, Әлмәт муниципаль районы Башкарма комитетының Икътисад һәм сәнәгать идарәсе башлыгы;

Комиссия әгъзалары:

Насыйров А.Б. – Әлмәт муниципаль районы Башкарма комитетының сәүдә, кулланучылар хезмәтләре күрсәтү һәм эшкуарлыкны үстерү бүлеге башлыгы;

Шаргина И.Н. – авыл җирлекләренең социаль инфраструктурасын үстерү секторы мөдире;

Шәйдуллина З.Р. - Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районының Финанс-бюджет палатасы рәисе.

2. Әлеге карарны «Альметьевский вестник» газетасында бастырып чыгарырга, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (PRAVO.TATARSTAN.RU) урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан соң үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны район Башкарма комитеты җитәкчесенең икътисад буенча урынбасары А.Ә. Ямалетдиновка йөкләргә.

Район
Башкарма комитеты җитәкчесе А.М. Каюмов